Татар мәктәбендә укучы балаларга татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр
9 нчы сыйныф 2016-2017 уку елы

**Үткәрү вакыты – 90 минут** **Максималь балл – *71***

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Сүзләр алфавит тәртибендә язылган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) игелекле, әдәпле, җиһан, дин; ә) Алия, Мансур, Рәшит, Сәйдәш;
   б) Әдилә, Дания, Самат, Илгиз; в) басма, капка, әрем, мәктәп.
2. Кыска әйтелешле сузык авазлар гына кергән сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) болыт, колак, торт, билет; ә) артист, планета, телефон, вымпел;
   б) йокы, борыңгы, керпе, төлке; в) директор, миләш, тема, бүре.
3. Басымы дөрес күрсәтелмәгән сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) бак-ча-чы-лы′к; ә) шу-га-лак-ла′р;
   б) шал-ты-ра-та-ла′р; в) ел-га-лар-ны′ң.
4. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең фразеологик вариантын билгеләгез. ***(2 балл)***
   *Рәмзия имтиханнар алдыннан бик нык **борчыла**.*
   а) чыраен сыта; ә) ут йота; б) тәлинкә тота; в) кул кушырып утыра.
5. Нигез төрләре дөрес күрсәтелмәгән сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***
   *Башла, көрәк, җилкуар, иртә-кич, сабан туе.*
   а) ясалма, ясалма, кушма, парлы, тезмә; ә) тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә;
   б) тамыр, тамыр, кушма, парлы, тезмә; в) тамыр, ясалма, кыскартылма, парлы, тезмә.
6. Җөмләдәге фигыльләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***
   *Күктә кояш булса, җирдә син бар,*
   *Миңа башка беркем кирәкми.*(Г.Гыйльманов)
   а) булса, бар, башка, кирәкми; ә) булса, бар, кирәкми; б) булса, бар; в) булса.
7. Җөмләдә тыныш билгеләре дөрес куелган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***
   *Бүген барысы да Алсу да Марат та Булат та һәммәсе дә бик матур итеп киенгәннәр*
   а) Бүген барысы да – Алсу да, Марат та, Булат та – һәммәсе дә бик матур итеп киенгәннәр.
   ә) Бүген барысы да – Алсу да, Марат та, Булат та: һәммәсе дә бик матур итеп киенгәннәр.
   б) Бүген барысы да: Алсу да, Марат та, Булат та, һәммәсе дә бик матур итеп киенгәннәр.
   в) Бүген барысы да: Алсу да, Марат та, Булат та – һәммәсе дә бик матур итеп киенгәннәр.
8. Сүзтезмә күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) гөмбә; ә) чебен гөмбәсе; б) зур гөмбә; в) Гөмбә үсә.
9. Җөмләдәге компонентлар санын билгеләгез. ***(2 балл)***
   *Сез каласыз инде, без китәбез,*
   *Без китәбез ерак илләргә.* (Г.Бәширов)
   а) 2 компонент; ә) 3 компонент; б) 4 компонент; в) 5 компонент.
10. Җөмләнең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***
    *Без, кармак салып арыганнан соң, балыкчы бабай янына барып, балык пешереп, чәй эчеп, кояш баер алдыннан гына кайта торган идек.* (М.Гафури)
    а) гади җөмлә; ә) тезмә кушма җөмлә;
    б) синтетик иярченле кушма җөмлә; в) аналитик иярченле кушма җөмлә.
11. Сөйләм өлешләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***
    а) автор сөйләме; ә) тыңлаучы сөйләме; б) чит сөйләм; в) автор сөйләме һәм чит сөйләм.
12. Туры сөйләмнең төрләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***
    а) диалог, монолог, цитата; ә) диалог, монолог; б) цитата; в) монолог, цитата.

## II. Теоретик бирем.

Эндәш сүзләр турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. ***(10 балл)***

## III. Грамматик һәм иҗади бирем.

Сүзләргә сузык авазлар өстәп, мәкальне языгыз, түбәндә бирелгән грамматик һәм иҗади биремнәрне үтәгез.

БР ГЛМ ЙЗ НДНН ҖҢР. ***(5 балл)***

1. Мәкальдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. ***(5 балл)***
2. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз. ***(5 балл)***
3. Икенче сүзгә фонетик анализ ясагыз. ***(5 балл)***
4. Мәкальдә кулланылган сүзләрдән мөмкин кадәр яңа сүзләр төзеп языгыз. ***(5 балл)***
5. Кайсы сүзнең омоним парлары бар, фикерегезне җөмләләр төзеп аңлатыгыз. ***(5 балл)***
6. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(7 балл)***